ГЛАВА
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «23» августыннан № 45

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган затка карарта опека һәм попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 3 июлендәге 42 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә,

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә сәләтле дип танылган балигъ булган затка карарта опека һәм попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 3 июлендәге 42 номерлы карарының үз көчен югалткан дип таныйрга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Аппарат җитәкчесенә йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов